**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасының аерым вәкиллекләре тарафыннан сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмати системаны файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты указларына кушымтада бирелүче исемлек нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 14 май
№ ПУ-410

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның « 14 » маендагы
ПУ- 410 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелүче үзгәрешләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеген гамәлгә кую турында» 1996 елның 25 маендагы ПУ-312 номерлы Указы нигезендә (Татарстан Республикасы Президентының 2002 елның 3 июнендәге ПУ-450 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Свердловск өлкәсендә даими вәкиллеге турында нигезләмәнең III бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 3.5 пунктын өстәргә:

«3.5. Вәкиллек ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән тәртиптә товарларны, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләрне сатып алырга.».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендә һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеген гамәлгә кую турында» 1996 елның 25 маендагы ПУ-314 номерлы Указы нигезендә расланган Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендә һәм Ленинград өлкәсендә даими вәкиллеге турында нигезләмәнең III бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 3.5 пунктын өстәргә:

«3.5. Вәкиллек ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән тәртиптә товарларны, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләрне сатып алырга.».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге тулы вәкаләтле вәкиллеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 8 сентябрендәге ПУ-346 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 11 августындагы ПУ-420 номерлы һәм 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1143 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге турындагы нигезләмәнең 12 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән тәртиптә товарларны, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләрне сатып алырга.».

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Башкортостан Республикасындагы даими вәкиллеген гамәлгә кую турында» 2011 елның 5 мартындагы ПУ-107 номерлы Указы нигезендә расланган Татарстан Республикасының Башкортостан Республикасындагы даими вәкиллеге турындагы нигезләмәнең 3.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә:

«9) Вәкиллек ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән тәртиптә товарларны, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләрне сатып алырга.».

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Кырым Республикасында һәм Севостополь шәһәрендәге даими вәкиллеге турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 6 маендагы ПУ-428 номерлы Указы нигезендә расланган Татарстан Республикасының Кырым Республикасында һәм Севостополь шәһәрендәге даими вәкиллеге турында нигезләмәнең 11 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә:

«9) Вәкиллек ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән тәртиптә товарларны, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләрне сатып алырга.».